БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«31» 10 2020 ел.

№ 310

«Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 5 июлендәге 254 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 5 июлендәге 254 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сату-алу үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентының (19 нчы кушымта) 1 нче кушымтасы Россия Федерациясе Җир кодексынан өземтәнең 2 пунктының 3.1 пунктчасын «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «алар турындагы белешмәләр Федераль закон нигезендә проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары төзелеше тәмамлангач» сүзләре белән тулыландырырга, «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының (1 нче кушымта)

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.5 пунктының 7 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сату-алу үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентының (19 нчы кушымта) 1 нче кушымтасы Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтәнең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 29.1 пункт белән тулыландырырга:

«29.1) дәүләт яки муниципаль милектә булган балык үрчетүчелек кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе (алга таба - балык үрчетүчелек кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе) нигезендә товарлы аквакультураны (товарлы балык үрчетү эшен) гамәлгә ашыручы затка күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлеге;».

2. Әлеге карарны интернет - ресурсында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (территориаль үсеш буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов